ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

№ 2 05.11.2020 ел

«Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлегенең Мюд поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы, Аксубай муниципаль районы, Мюд поселогы, Үзәк урамы, 35 нче йорт адресы буенча урнашкан Мюд авылы мәдәният йорты бинасы янында 2020 елның 19 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Мюд авыл җирлеге Мюд поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган торучыдан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүенә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Мюд поселогы торак пункты чикләрендә вак ташҗәелгән юл полотносы урнаштыру (грунтлау, грейдерлау, вак таш җәю, ком сибү, килешү буенча эшләр өчен түләү)
- Мюд поселогы торак пункты чикләрендә кышкы чорда автомобиль юлларын карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны авыл җирлеге халкы күпләп җыела торган урыннарда, стендларда һәм такталарда элеп кую юлы белән, шулай ук Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

ТР Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т. В. Зюзина